# *Ибрагимова Васфи Сәләхи кызы*.

*Мин, Ибраһимова Васфи Сәләхи кызы, 1936 нчы елның 2 нче сентяберендә тудым. 1941 нче елда әтием сугышка китте, ә 1942 нче елда "үлде" дигән хат килде. Сугыш башланганда, миңа 4 яшь иде. Әти киткәндә, "Кызым, кайтырмын",- дип әйтеп калдырды. Казакларда укыдым, 2 сыйныф та бетермәдем. Ул вакытта бик авыр иде, ашарга юк, кияргә кием юк, аякта чабата. Күкәрин, кычыткан, бәрәңге сабагы ашап яшәдек.*

*1958 нче елны Юваска килен булып төштем. Башта сарык карадым, аннары колхозда сыер карадым. Медальләрем бик күп минем!*

*Хәзерге буынның тырышып укуын, ялкауланмавын, олыларның сүзен тыңлауларын, начарлык юлына басмауларын телим.*

